| РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО<br>КОМИТЕТА БУГУЛЬМИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 1 март г.Бугульма № 185

**Бөгелмә муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне оештыру һәм үткәрү буенча функцияләр административ регламентын раслау турында**

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль норматив хокукый актларның үтәлешенә муниципаль контрольне тормышка ашыру буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру максатларында, шулай ук "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294 номерлы ФЗ Федераль закон һәм административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә карар бирәм:

1. Бөгелмә муниципаль районы территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне оештыру һәм үткәрү буенча функцияләр административ регламентын кушымта буенча расларга (Кушымта 1)

2. Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр бүлегенә әлеге карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә аны Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыруны тәэмин итү.

3. Әлеге карарны тормышка ашыруда контрольне Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад үсеше сораулары буенча урынбасары М.Р. Болгаковка йөкләргә.

А.Р. Галиуллин